Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Васильевка авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

05 ноябрь 2019 ел № 21

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Васильевка авыл җирлегенең
Васильевка авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең Васильевка авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2019 елның 19 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Васильевка авыл җирлегенең Васильевка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: « Васильевка авылы мәдәният йорты бинасының фасадын ремонтлау һәм тәрәзәләрен алыштыру (чыгым материаллары, металлосайдинг, тәрәзә блоклары һәм комплектлау әйберләре сатып алу)?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын Васильевка авыл мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Васильевка авылы, Үзәк урамы, 26 нчы йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Васильевка авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Васильевка
авыл җирлеге башлыгы Ш.М. Касыймуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ВАСИЛЬЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ОГРН 1021601634263
ВАСИЛЬЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ
ИНН1644013931
КПП164401001